ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады хакында

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе З.Р. Вәлиева тарафыннан тәкъдим ителгән «2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында»гы докладны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы алдында торучы бурычларны хәл итүдә җәмгыятьне берләштерү буенча гражданнар инициативаларына актив ярдәм итү, коммерциягә карамаган оешмаларның, граждан җәмгыятенең башка институтларының ролен арттыру эшен дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре иҗтимагый советларының иҗтимагый контроль буенча тәкъдимнәрен гомумиләштерергә, иҗтимагый контрольнең нәтиҗәлелеген арттырырга.

2.3. Традицион гаилә кыйммәтләрен саклау һәм үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү эшендә актив катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына «2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне, шул исәптән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы иҗтимагый советлар һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре иҗтимагый советлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруны, тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына коммерциягә карамаган оешмаларга илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларындагы региональ проектларда аларны башкаручылар буларак катнашуларына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән бергә 2024 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре иҗтимагый советлары эшчәнлеген җайга сала торган документларга үзгәрешләр кертүне тәмамлауны тәкъдим итәргә.

6. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына, эксперт берләшмәләрен, коммерциягә карамаган секторны җәлеп итеп, Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышына һәм үсешенә багышланган махсус программалар (тапшырулар) әзерләү буенча тәкъдимнәр кертүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына «2023 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карарга һәм алар буенча кирәкле чаралар күрергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2393-VI ДС